| | |
|---|---|
| **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТСПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 39 22 июнь 2020 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Болгар шәһәр Башкарма комитетының
Спас муниципаль районы Болгар шәһәр башкарма
комитеты тарафыннан 2020 елның 3 февралендә
кабул ителгән "Спас муниципаль районы Болгар шәһәр
башкарма комитеты тарафыннан элек
хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль
милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында" гы
8 номерлы карары белән расланган административ регламентка
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм административ регламентларны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 3 февралендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

1.1. 13 пунктның 2.15 абзацын төшереп калдырырга;

1.2Административ регламентның 5 бүлегенең исемен яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның йә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның яисә аларның

хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка (судтан тыш) шикаять белдерү».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Спас муниципаль районы<br>Болгар шәһәре Башкарма комитеты<br>җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.А.Кузнецов